**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 4 сентябре** **№ 90**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2017 елның 14нче ноябрендәге “Җир салымы турында”гы 70 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2017 елның 14нче ноябрендәге “Җир салымы турында”гы 70 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның 6нчы маддәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6нчы маддә. Салым базасын киметү

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә салым базасын (салымны тотып калуны) киметү салым түләүченең сайлавы буенча бер җир кишәрлегенә карата башкарыла.

Сайланган җир кишәрлеге турындагы мөрәҗәгать (ул кишәрлектән салым тотып калу кулланыла), салым түләүче тарафыннан үзенең теләге белән салым органына, салым чоры булган елның 1нче ноябренә кадәр тапшырыла. Шул чордан башлап күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата салымны тотып калу кулланыла”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк ур., 1 йорт,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, 2-нче Клубная ур., 14 йорт,шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Яңасала авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Яңасала авыл җирлеге

Советы рәисе И.Х. Шиһабиев